ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә һәм әлеге өлкәдә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруда аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) җиңел такси – гавами фрахтлау шартнамәсе нигезендә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган җиңел автомобиль;

2) рөхсәт – Федераль законның 3 статьясының 1 өлеше нигезендә юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә физик зат тарафыннан җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын бирә торган электрон документ;

3) физик зат – «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы һәм индивидуаль эшкуар булмаган зат;

4) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы – Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Закон нигезендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә физик зат;

5) җиңел таксига заказ бирү хезмәте – фрахтлаучы һәм фрахтчы тарафыннан алга таба җиңел таксины фрахтлауның гавами шартнамәсен төзү максатларында

фрахтлаучы булырга ниятләгән заттан җиңел таксига заказ алу һәм (яисә) фрахтчы булырга ниятләгән затка җиңел таксига заказ тапшыру эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелгән юридик зат яисә индивидуаль эшкуар.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру һәм җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләү;

2) рөхсәт бирү, аның гамәлдә булуын туктатып тору, юкка чыгару һәм торгызу тәртибен билгеләү;

3) вәкаләтле органга Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гаризаны яисә хәбәрнамәне һәм аларга кушып бирелә торган документларны җибәрү тәртибен билгеләү;

4) җиңел такси йөртүчеләр турындагы белешмәләр составын һәм вәкаләтле органга җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан әлеге белешмәләрне җибәрү тәртибен билгеләү;

5) вәкаләтле орган җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрына һәм (яисә) җиңел таксилар региональ реестрына керткән үзгәрешләр турындагы белешмәләрне алуның техник мөмкинлеге булмау хакындагы хәбәрнамәне вәкаләтле органга җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан җибәрү тәртибен билгеләү;

6) җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләргә һәм багаж ташучыларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр, аларның бәясе һәм алар өчен түләү кагыйдәләре турындагы белешмәләрне үз эшчәнлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланмыйча гамәлгә ашыручы җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан урнаштыру тәртибен билгеләү;

7) җиңел таксига заказ бирү хезмәте үз эшчәнлеген «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланмыйча гамәлгә ашыруны күздә тоткан очракта, Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны җиңел таксига заказ бирү хезмәте тарафыннан урнаштыру тәртибен һәм чыганакларын билгеләү;

8) физик зат булган җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы (рөхсәт алу турында гариза бирергә ниятләгән зат) (алга таба – заказчы) тарафыннан вәкаләтле органга, заказчы җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлаганчы, заказчыга җиңел такси турындагы белешмәләр җиңел таксилар региональ реестрына кертелгән җиңел таксины файдалануга бирү, аны

бирү срогы турында хәбәрнамә тапшыру, шулай ук аны исәпкә алу тәртибен билгеләү;

9) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан җиңел таксига заказ бирү хезмәтенә җиңел такси йөртүченең Федераль законның 19 статьясындагы 3 өлешенең 8 пунктында каралган таләпләрне бозуы турында белешмәләр тапшыру тәртибен билгеләү;

10) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау;

11) Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

12) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) рөхсәт бирү, аның гамәлдә булуын туктатып тору, юкка чыгару һәм торгызу;

2) җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукын бирү, җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукының гамәлдә булуын туктатып тору, бетерү һәм торгызу;

3) җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрын, җиңел таксилар региональ реестрын һәм җиңел таксига заказ бирү хезмәтләре региональ реестрын (алга таба – региональ реестрлар) алып бару;

4) җиңел таксида пассажирлар йөртүче һәм багаж ташучы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифлары турындагы белешмәләрне урнаштыру өчен Федераль законның 24 статьясындагы 2 өлешендә каралган сайтны билгеләү;

5) Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешендә каралган гаризалар һәм хәбәрнамәләр, әлеге гаризаларга карата карарлар кабул итү турындагы хәбәрнамәләр һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрыннан, җиңел таксига заказ бирү хезмәтләре региональ реестрыннан өземтәләр рәвешләрен раслау;

6) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

7) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру**

1. Җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеге, җиңел таксилар региональ реестрына алар турында белешмәләр кертелгән транспорт чараларыннан файдаланып, юридик затка, индивидуаль эшкуарга яисә физик затка бирелә торган һәм җиңел таксида пассажирлар йөртүчеләр һәм багаж ташучылар региональ реестрындагы язма белән расланган рөхсәт нигезендә, рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тормау яисә юкка чыгармау шарты белән, гамәлгә ашырыла.

3. Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга рөхсәт биш елга, физик затларга рөхсәт биш елга йә, физик зат рөхсәт алу турындагы гаризада азрак срокны күрсәткән очракта, шул срокка бирелә.

4. Җиңел таксига заказ бирү хезмәте эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукы бирелә торган срок биш ел тәшкил итә.

6 статья. **Җиңел таксига карата куела торган таләпләр**

1. Җиңел такси Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш. Җиңел такси кузовының төсләр гаммасы ак яисә сары төсләр гаммасына туры килергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлешендә каралган мәгълүматны ике үлчәмле штрихлы код (QR-код) рәвешендә яисә җиңел такси салонында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге мәгълүмат урнаштырылган сайтның адресы турындагы белешмәләрне урнаштыру аша бирү мөмкинлеге билгеләнергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән җиңел такси буларак файдаланыла торган транспорт чарасының экологик классына карата өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.

7 статья. **Региональ реестрлар**

1. Региональ реестрларны алып бару, җиңел таксилар федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.

2. Җиңел таксилар федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган белешмәләр составы, вәкаләтле орган тарафыннан белешмәләрне мондый мәгълүмат системасына тапшыру тәртибе, сроклары, ысуллары Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган җиңел таксилар федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

8 статья. **Аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру үзенчәлекләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән, аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрне

тәкъдим итү һәм (яисә) рәсмиләштерү өчен җиһазландырылган урыннардан тыш, мондый хезмәт күрсәтүне тәкъдим итүне тыю, аэропортлар, тимер юл вокзаллары һәм автовокзаллар территорияләрендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру үзенчәлекләре билгеләнергә мөмкин.

9 статья. **Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган нигезләмәгә таянып башкарыла.

2. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып Федераль законның 30 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү тора.

3. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

4. Җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып даими рейд үткәрелә. Даими рейдны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә.

10 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш);

2) «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 20 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 4 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 77 (I өлеш).

11 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

2. Вәкаләтле орган тарафыннан 2023 елның 1 сентябренә кадәр бирелгән җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәтләр аларның гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы, әмма күрсәтелгән датадан биш елдан күбрәк түгел, гамәлдә булалар.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 71-ТРЗ